**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Налим торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

**20.11.2024** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлегенең Налим торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2025 елда Югары Налим авыл җирлегенең Налим торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә, белем бирүнең көндезге формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга:

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (беседканы китерү, җыю һәм урнаштыру (монтажлау); юлны вак таш белән ясау).

3. Карарны кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Зәй муниципаль районы
Югары Налим авыл җирлеге башлыгы Л.И. Сибгатуллин